КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 27 декабрь г.Казань № 1042

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 елга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумын раслау турында» 2016 ел, 29 декабрь, 1048 нче карары белән расланган 2017 елга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 елга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумын раслау турында» 2016 ел, 29 декабрь, 1048 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 30 июнь, 452 нче, 2017 ел, 5 октябрь, 762 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган 2017 елга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 бүлекнең 6.1 пунктында:

6.1.6 пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«16) «Татарстан Республикасы территориясендә тутыгуга каршы һәм барьер япмалар җитештерүне оештыру» («Тат-Адвенира» ҖЧҖ, Казан шәһәре).»;

6.1.8 пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«7) ««Цеолитлы токымнарның Татар Шатрашаны чыганагын эшкәртү һәм товар продукциясе җитештерүне оештыру» («Идел буе цеолитлары» ААҖ, Чүпрәле муниципаль районы).»;

6.1.15 пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

61) «Мастер» Кама индустриаль паркын үстерүнең 4 нче чираты» («Мастер» Кама индустриаль паркы» АҖ, Чаллы шәһәре);

62) «Мастер» Кама индустриаль паркын үстерүнең 5 нче чираты» («Мастер» Кама индустриаль паркы» АҖ, Чаллы шәһәре).»;

6.1.15 пунктчаның икенче абзацын төшереп калдырырга;

6.1.6 пунктчаның сигезенче абзацын төшереп калдырырга;

6 бүлекнең 6.2 пунктында:

6.2.4. пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2) «Түбән Кама шәһәрендә акрынайтылган кокслаштыру урнаштыру» (В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАЖ, Түбән Кама муниципаль районы).»;

6.2.5. пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«7) «Түбән Кама шин » ГАЖ әзерлек җитештерүен төзекләндерү» («Түбән Кама шин » ГАЖ, Түбән Кама шәһәре, сәнәгать зонасы).».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин